**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2017 ел, 21 март

№ 173

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын формалаштыруга һәм кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗын фаразлау регламентын раслау турында» 2014 ел, 31 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын формалаштыруга һәм кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗын фаразлау регламентын раслау турында» 2014 ел, 31 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 15 февраль, 81 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның өченче абзацында «2015 елдан башлап» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына үз эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына студентларны кабул итүнең контроль саннарын формалаштырганда исәпкә алу өчен Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгына Татарстан Республикасы икътисадының Татарстан Республикасының югары һәм урта һөнәри белемле кадрларына ихтыяҗы фаразын җибәрүне оештырырга.»;

5 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. «Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре

ассоциациясе» төбәк эш бирүчеләре берләшмәсенә, Татарстан Республикасының кече һәм урта бизнес предприятиеләре ассоциациясенә, эш бирүчеләрнең башка берләшмәләренә тармак министрлыклары белән берлектә тәкъдим итәргә:»;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кадрлар квалификациясен бәйсез бәяләү үткәрү һәм Квалификация бәяләү үзәге төзү буенча эшне башлап җибәрергә;»;

өченче абзацны төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 6[1] пункт өстәргә:

«6[1]. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказына кергән белем бирү программалары буенча студентларны кабул итүнең контроль саннарын формалаштырганда кабул итүнең контроль саннарын дәүләт заказы күләменнән 15 проценттан артмаган күләмдә кертергә.»;

әлеге карар белән расланган Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын формалаштыруга һәм кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗын фаразлау регламентында (алга таба – Регламент):

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«мәгариф оешмаларына кабул итүнең контроль саннары – мәгариф оешмалары алар чикләрендә кабул итүне гамәлгә ашырырга хокуклы федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетларның бюджет ассигнованияләре исәбеннән урта һөнәри белем һәм югары белем бирү программалары буенча укучылар саны.»;

3 пунктта «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Тармакның бер елга (муниципаль берәмлекнең) урта һөнәри белем һәм югары белем бирү программалары буенча әзерләүгә ихтыяҗы югары һәм урта һөнәри белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларны эш урыннарына алуга теләкләре булу турында потенциаль инвесторлар белән килешүләрдә каралган Татарстан Республикасы икътисад тармагының эре предприятиеләренең (кече һәм урта предприятиеләрнең, шулай ук инвестиция проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен үстерү стратегияләрен тормышка ашыру кысаларында төзелә торган яңа предприятиеләрнең) ихтыяҗын үз эченә ала.»;

6 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль берәмлекнең югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча әзерлеккә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә ихтыяҗларын фаразлаганда

исемлекләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары белән раслана торган кече һәм урта предприятиеләрнең, инвестиция проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен үстерү стратегияләрен тормышка ашыру кысаларында төзелә торган яңа предприятиеләрнең ихтыяҗларын, кече һәм урта предприятиеләрдә булган хезмәт ресурсларын, өстәмә төзелә торган яңа һәм буш эш урыннарын, шулай ук табигый кимү һәм штатлар саны кыскару белән бәйле хезмәткәрләрнең китүен исәпкә алырга кирәк;»;

11 пунктта:

икенче абзацта «15 апрельгә кадәр» сүзләрен «15 майга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацка «(Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказына һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказына Татарстан Республикасы икътисадын үстерүнең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган, ихтыяҗ булган профессияләр һәм белгечлекләр исемлегенә кертелгән, тиешле әзерлек белгечлекләре (юнәлешләре) һәм белем бирү программалары буенча кадрлар әзерләү ихтыяҗы күләменнән артмаган күләмнәрдә урта һөнәри белем белгечлекләре, югары белем әзерләү һәм һөнәри әзерлек юнәлешләре керә)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле яңа 12 пункт өстәргә:

«12. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына үз эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы югары белем бирүче мәгариф оешмалары белән алар белем бирү оешмаларына кабул итүнең контроль саннары проектын формалаштырганда югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗын фаразлау мәгълүматларын исәпкә алу турында һәм бакалавриат, магистратура һәм белгечлек программалары буенча укырга керүчеләр хакында, шулай ук, белгечлеген күрсәтеп, укучылар һәм укуны тәмамлаучылар турында килешүләр төзергә.»;

Регламентка 2 нче кушымта исемендә «кече һәм урта предприятиеләрнең» сүзләреннән соң «, шулай ук инвестиция проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен үстерү стратегияләрен тормышка ашыру кысаларында төзелә торган яңа предприятиеләрнең» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\173.doc